ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «МИЧУРИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МИЧУРИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 20 октябре № 15

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 6 декабрендәге 19 номерлы карары белән расланган Җирлек зиратында җирләү урыннарын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 6 декабрендәге 19 номерлы карары белән расланган Җирлек зиратында җирләү урыннарын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә башкару үзенчәлекләре.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы

«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Р.А.Иванова